РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
НОВОЧЕЧКАБСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 октябрь 2021 ел № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
куллану мәсьәләсе буенча ТР Буа муниципаль
районының Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Чәчкап
торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге Уставының 11 һәм 22 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәкап авылы җирлегенең Яңа Чәчкап авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны 2021 елның 2 ноябренә 10.00 сәгатькә билгеләргә. Гражданнар җыенын үткәрү өчен җаваплы итеп, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Чәчкап авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Яңа Чәчкап авылы гражданнары җыенының 2019 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә җыелган гражданнарның үзара салым акчаларын Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларга һәйкәл төзүгә һәм Яңа Чәчкап авылында юлларны ремонтлауга, түбәндәге эш төрен үтәү буенча җибәрүгә Сез ризамы:

- Яңа Чәчкап авылында юлларны ремонтлауга?».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

Буа муниципаль районының
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы Д.Д. Абдрахманова